**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның «25» гыйнварыннан № 23

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр прейскурантын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле һәм керем китерә торган башка хезмәтләр күрсәтү турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 2023 елның 29 декабрендәге 40-325 номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары нигезендә, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр күрсәтүне тәртипкә салу максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Кушымтада бирелгән «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр прейскурантын расларга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет мәдәният

учреждениесе тарафыннан эшчәнлектән керем китерүче түләүле хезмәтләр күрсәтү турында Нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 17 августындагы 198 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ИНН 1631003397
ОГРН 1051660041740

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның «25» гыйнварындагы
23 номерлы карары белән
расланган

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр прейскуранты

| № т/б | Хезмәтнең атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе |
|---|---|---|
| 1 | Газета һәм журналларның еллык тегелмәсендә бер тапкыр эзләү | 20 сум |
| 2 | Гамәлдәге законнар кысаларында китапханә ябылганнан соң (төнге абонемент), укучылар залыннан басмалар бирү | 5 сум<br>Тәүлеккә 1 экз. |
| 3 | Ихтыяҗ зур булган әдәбият бирү | 5 сум<br>Тәүлеккә 1 экз. |
| 4 | китапханә материалларының һәм куллануча материалларының А4 форматындагы ксерокопияләрен ясау | 5 сум<br>бер бит |
| 5 | Текстны сканерлау | 35 сум |
| 6 | Компьютер уеннары программаларын файдалану | 15 сум<br>1 сәгать |
| 7 | Факс буенча мәгълүмат җибәрү | 20 сум<br>1 бит |
| 8 | Интернетка керү мөмкинлеге белән компьютер вакыты бирү | 50 сум<br>0,5 сәгать |
| 9 | Компьютерда текст җыю:<br>заказчы кульязмасыннан<br>машина текстыннан | А4 форматы - 30 сум<br>А4 форматы - 25 сум |
| 10 | Абнементта бирелгән китаплардан файдалану срокларын бозган өчен штраф, бер тәүлек срок узгач | 5 сум |
| 11 | Аттракционнардан файдалану | 2 минут - 50 сум |